Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Олы Талкыш авыл җирлеге Советы

2021 елның 26 октябре №14/3

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге Советының «Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2018 елның 23 июлендәге 24/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 июлендәге 24/1 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.»;

12 статьяның өченче абзацында «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3.1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Олы Талкыш авыл җирлеге
башлыгы Э.Б. Ильин